**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

Исполнительный комитет
Агерзинского сельского поселения
Азнакаевского муниципального
района

423303, Азнакаевский район, с.
Агерзе, ул.Г.Ахметовой, д.9а
тел.8(855-92)44-5-21
E-mail: Ager.Azn@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

Азнакай муниципаль районы
Әгерҗе авыл җирлеге башкарма
комитеты

423303, Азнакай районы, Әгерҗе
авылы, Г.Ахметова урамы, 9а
тел.8(855-92)44-5-21
E-mail: Ager.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

от «08» 02 2021 ел № 3

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлеге башкарма комитетының 2017 елның 13 нояберендәге. 27 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлеге башкарма комитетының резерв фондыннан акчалар тоту тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлеге башкарма комитетының резерв фондыннан акчалар тоту тәртибе турында нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында (2018 елның 14 февралендәге 4 номерлы карар редакциясендә)

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе,Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык идарәсенең 2020 елга Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетын фаразланган үтәү йомгаклары һәм республиканың финанс, казначылык һәм салым органнарының 2021 елга бурычлары буенча 2021 елның 04 гыйнварындагы ПР-3 номерлы уртак коллегия беркетмәсенең 24,25 пунктларын үтәү йөзеннәнТатарстан Республикасы Әгерҗе авыл җирлеге Башкарма комитеты карар итә:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлеге Башкарма комитетының 2017 елның 13 нояберендәге 27 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлеге башкарма комитетының резерв фондыннан акчалар тоту тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлеге башкарма комитетының резерв фондыннан акчалар тоту тәртибе турында нигезләмәгә (2018 елның 14 февралендәге 4 номерлы карар редакциясендә), 5 нче пунктны түбәндәге эчтәлекле 3 нче абзац өстәп, үзгәреш кертергә:

«Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлеге Башкарма комитетының Резерв фондыннан акча алу шарты булып, Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр түләү буенча бурычлар (үтәлмәгән) булмау тора.».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» http//pravo.tatarstan.ru. веб – адресы буенча урнаштыру юлы белән һәм Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында http//aznakayevo.tatar.ru адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башлык: Н.Н.Хәсәнов